# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Түбән Пошалым авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

**“15” ноябрь 2023 ел** **№ 8**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 15 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Түбән Пошалым авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 305 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 610 сум күләмендә үзара салым кертү шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Җирле әҺәмияттәге юлларның буйга профилен төзәтү.
2) Агачларны санитар кисү һәм зират территориясеннән чыгару.
3) Пионер урамындагы 30нчы йорт янындагы канауны вак таш белән тутыру.
4) Торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту?»

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

Халык җыены нәтиҗәләре беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 172 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 92 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде: "Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 92 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Түбән Пошалым авылында халык җыенын булып узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Түбән Пшалым авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 305 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 610 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын)

түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Җирле әҺәмияттәге юлларның буйга профилен төзәтү.

2) Агачларны санитар кисү һәм зират территориясеннән чыгару.

3) Пионер урамындагы 30нчы йорт янындагы канауны вак таш белән тутыру.

4) Торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту?»

- мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә, Үрнәк авыл җирлеге, Түбән Пошалым авылы мәгълүмат стендында, Арча муниципаль районның (http://arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Үрнәк авыл җирлеге башлыгы В.Р.Габделхаков